РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422075, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, 23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы, Явлаштау авылы, Ш Бариев урамы, 23 йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.03.2025

КАРАР
№ 20

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитетының 09.03.2016 елгы №10 карары белән расланган Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитетының гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм вазыйфаи затларның шәхси кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында " 28.12.2024 ел, №547-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитетының 09.03.2016 елгы №10 карары белән расланган «Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитетының гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибен раслау турында» гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитеты вазыйфаи затларының шәхси кабул итү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1.** 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1 Гражданның мөрәҗәгате (алга таба — мөрәҗәгать) — "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба - Бердәм портал), дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасыннан йә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының рәсми сайтыннан файдаланып, язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка гражданнарны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итүче "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең (әгәр әлеге Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса) тәкъдиме, гаризасы яисә шикаяте, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;»;

**1.2.** 6 нчы бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гражданның мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә аның иминлеге гарантияләре.

6.1. Күрсәтелгән органнарның яки вазыйфаи затның эшчәнлеген тәнкыйтьләп җирле, үзидарә органына яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгать иткәнгә йә үз хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен йә башка затларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау максатларында гражданны эзәрлекләү тыела.

6.2. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне, шулай ук гражданның хосусый тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт ителми. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне ачу булып тормый.

6.3. Гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатларында аларның оператив-эзләү эшчәнлеген яисә Россия Федерациясенең иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләрне Эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, иминлекне тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, Тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, дәүләт саклавы өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән электрон документ формасына һәм мөрәҗәгатьләргә җавапларны, хәбәрнамәләрне җибәрүгә махсус тәртип урнаштырылырга мөмкин..»;

**1.3.** 7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.Дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать әлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан мәҗбүри тәртиптә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), электрон почта адресын йә шәхси кабинет адресын бердәм порталда яисә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының гражданны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итә торган башка мәгълүмат системасында, әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, һәм почта адресын, әгәр җавап язма формада җибәрелгән. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә теркәргә йә күрсәтелгән документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.».

2. Әлеге карар 2025 елның 30 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Явлаштау авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев